# КАРАР

## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советы карары

Үчәлле авылы № 128 28 гыйнвар, 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрендәге 52 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының " Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (05.10.2013 ел, №75, 17.03.2014 ел, №91, 15.08.2014 ел, №112, 25.08.2017 ел, № 63)

2017 елның 29 декабрендәге 463 номерлы Федераль закон нигезендә-«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының» Үчәлле авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыңц «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Үчәлле авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 октябрендәге 52 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (05.10.2013 ел, №75, 17.03.2014 ел, №91,

15.08.2014 ел, №112, 2017 елның 25 августындагы 63 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче, өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны карап тотуга юнәлтелгән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге.

Төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.10.3.1 пунктын өстәргә:

"2.10.3.1. Йорт билгеләренә, тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәп, урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш, дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат буенча рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәренең http://aznakyevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәисе Г. М. Төхвәтуллина